# Файдалы семинар.

Бүген белем бирү системасы, мәгариф өлкәсендәге үзгәрешләр заман дәресләренә яңа таләпләр куя. Шушы максаттан чыгып укытучылар эш тәҗрибәләре белән төрле семинарларда уртаклаша, белемне камилләштерү курсларында була.

Район мәктәпләренең сынлы сәнгать укытучыларының чираттагы эш семинары Калтай урта мәктәбендә узды. Методист Лукманова Зөлфия Мөдәрис кызы белән килгән мөгаллимнәрне мәктәп җитәкчелеге ихлас кабул итте. “Федераль дәүләт белем бирү стандартлары шартларында сынлы сәнгать укытучыларының педагогик осталыгын камилләштерү” темасы астында үткән бу чарада Калтай урта мәктәбе укытучылары эш тәҗрибәләре белән уртаклашты. Нуриева Зөлфия Мансаф кызы 5 нче сыйныфта “Бизәнгечләр халыкка нигә кирәк? “ темасы буенча заман таләпләренә туры килгән ачык дәрес күрсәтте.Мөгаллимә үз эшенең остасы икәненә без бик инандык. Ул укучылар белән ачык , ягымлы мөгаләмәдә, тормыш белән бәйләп, бизәнгечләрнең борынгы чорлардан ук чагылышы һәм әһәмияте турында эчтәлекле , зәвыклы мәгълүмат бирде. Үзаллы эшне барлык укучылар да тырышып башкарды.

Шулай ук Гилманова Гөлназ Зәбир кызы һәм Шафина Лидия Зәбир кызы үткәргән “Салват күпере төсләре” дәрестән тыш чара да семинарда катнашучыларда уңай тәэсирләр калдырды.

Бүген тормышыбызда балаларның иҗади сәләтен төрле алымнар һәм чаралар кулланыла. Районның гимназия укытучысы Әхтәмова Лилия Илгиз кызы сынлы сәнгать укытучыларына “Эбру техникасы буенча рәсем төшерү” исемле мастер-класс тәкъдим итте һәм шушы алымның үзенчәлекле үрнәкләре белән таныштырды.

Калтай мәктәбе укучыларының Бөек Җиңүнең 75-еллыгына багышланган сыйныфтан тыш чарада сугыш һәм тынычлык турында яңгыраган шигырьләре, җырлары, башкарган биюләре дә күңелләргә хуш килде.

Гимназиянең сынлы сәнгать укытучысы Әбдуллина Айгөл Хәниф кызы “Сынлы сәнгать дәресләрендә төрле традицион булмаган чаралар куллану” исемле чыгышында, укучыларының иҗади эшләре белән таныштырды, дәресләрне үткәрүдә шушы чараларны куллану яхшы нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итүен ассызыклады.

Семинар бик тә җанлы, эчтәлекле, файдалы үтте. Чараны үткәрүче хуҗаларга, оештыручы методист Зөлфия Мөдәрис кызына рәхмәт белдерәбез, яңа уңышлар телибез.

Илек урта мәктәбе укытучысы Вәлиева З.Д.